Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАРЫ

24.12.2021 ел — Менделеевск ш. — №89

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының 2014 елның 24 декабрендәге 109 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маеннан 59 номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маеннан 16 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы мөрәҗәгатьләрен карау эшен камилләштерү максатларында:

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының 2014 елның 24 декабрендәге 109 номерлы карарының 4 пунктындагы икенче абзацына үзгәрешләр кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җавап хатларына - муниципаль район башлыгы урынбасары, муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе, муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарларына үз компетенцияләре нигезендә имза салуга».

2. 2.15 пунктына кертергә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының 2014 елның 24 декабрендәге 109 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районы башлыгы һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьләрен карау эше тәртибенә үзгәрешләр кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Язма мөрәҗәгатькә җавап Менделеевск муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, Менделеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, шулай ук аның урынбасарлары тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә имзалана»

Башлык урынбасары — Л.К.Галеева